РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

05.08.2015 ел №295

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»2009 елның 7 августындагы 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2009 елның 7 августындагы 155 номерлы карарына (28.09.2011 ел №58, 18.04.2012 ел №77, 04.09.2012 ел №117, 08.10.2012 ел №123, 05.04.2013 ел №157, 29.10.2013 ел №189, 30.12.2013 ел №202 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

« - Хокукый экспертиза үткәрү өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (13 нче кушымта)» кушымта итеп бирелә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
муниципаль район Советы рәисе урынбасары М.Т. Батыршина

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2009 елның
7 августындагы 155 номерлы
карарына 13 нче кушымта

**Хокукый экспертиза үткәрү өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме**

1. Хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларны юрист сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) өчен айлык өстәмә вазыйфаи окладның 25% күләмендә билгеләнә.

2. Өстәмә аның күләмен тиешле җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенең хокукый акты белән билгеләгәннән соң түләнә.

3. Өстәмә муниципаль хезмәткәрнең акчалата кереме белән бер үк вакытта түләнә.